**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

2024елнын «01» феврале 8-РС номер

# КАРАР

**«Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2022 елның 23 декабрендәге 103-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Устав нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2022 елның 23 декабрендәге 103-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

1) 2.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-әлеге Тәртиптә күрсәтелгән гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай бирү (тапшыру) турындагы мәгълүмат дәүләт мәгълүмат системасында социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**